ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» апреля 2021 ел №100

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына
Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Энгельс ур., ж/к 5
адресы буенча җир кишәрлеген кертү турында

«Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервлау турында» 2004 елның 22 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын, «Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервын булдыру чаралары турында» 2004 елның 3 ноябрендәге 210 номерлы Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсен, «Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервын формалаштыру тәртибе турында» 2004 елның 21 декабрендәге 255 номерлы Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы җирләрнең Дәүләт резерв фондының һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү һәм алардан соңгы файдалану мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлек тәртибен раслау турында» 2005 елның 21 гыйнварындагы 15 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Торак пунктлар җирләреннән 860 кв.м мәйданлы, кадастр номеры 16:01:220208:160 булган, Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Әгерҗе ш., Энгельс ур., ж/к 5 адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертергә.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (https://agryz.tatarstan.ru) составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**